| | |
|---|---|
| **ГЛАВА УЛЬЯНКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УЛЬЯНКОВО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 ноябрь, 2021 ел Ульянково ав. № 4

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Ульянково
авыл җирлегенең Воскресенский авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 23 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Воскресенский авылы, Леваневского урамы, 10 нчы йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Воскресенский торак.пунктында үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең Воскресенский авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Ульянково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч

муниципаль районы Ульянково авыл жирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл жирлеге башкарма комитеты гражданнар җыенын үткәргәндә Ульянково авыл жирлеге территориясендә яңа коронавирус йогышы (COVID-19) авыруы очракларын кисәтү һәм тарату өчен профилактик, санитар-эпидемияләргә каршы чараларны үтәүне тәэмин итәргә.
5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Ульянково авыл жирлеге башлыгы** **Ф.А. Сундурова**